БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
9 октябрь 2020 ел

**КАРАР**
№ 9

## «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. 1 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проектын беренче укылышта хупларга һәм гамави тыңлауларга чыгарырга.
2. 2 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен расларга.
3. 3 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проекты буенча гамави тыңлаулар үткәрү тәртибен расларга.
4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары проекты буенча гамави тыңлауларны түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Балтач ш.т. п., Ленин ур., 42 нче йорт, 3 кат. Гамави тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 2020 елның 2 ноябре, 13.00 сәгатьтә.
5. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р.Р. Нотфуллин